СОВЕТ НОВОМЕЛЬКЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА МЭЛКЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423728,Республика Татарстан,
Мензелинский район, с,Новый Мелькен
ул.Школьная, 17а

423728, Татарстан Республикасы,
Минзәлә районы, Яна Мэлкэн авылы, Школьная ур..17а

телефон: (85555)2-37-25. E-mailNmelMnz@tatar.ru
ОКПО 04308261 ОГРН 1021605552825 ИНН/КПП 1628002876/162801001

КАРАР

№1 16.09.2019 ел.

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Яңа Мәлкән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында”**

Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Яңа Мәлкән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасының 2018 елның 16 мартындагы “Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үиздарә турында”гы №45-ЗРТ” Законына үзгәрешләр кертү турындагы №10-ЗРТ Законы нигезендә, Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы “Яңа Мәлкән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертергә:

1.1 22 маддәсенең 2 өлеше, 2 п.пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) яңадан барлыкка килгән җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук сайлау хокукына ия булган халык саны 300 дән күбрәк булса, яңадан барлыкка килгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләләре буенча авыл арасындагы территориядә урнашкан торак пунктта;

1.2 19 маддәсенең 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирле әһәмияттәге мәьәләләр буенча муниципаль норматив-хокукый актлар проектларын тикшерү өчен Җирлектә яшәүчеләр, Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, Җирлек Башкарма комитеты катнашында ачык тыңлаулар уздырылырга мөмкин”.

1.3 19 маддәсенең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар халык яисә Җирлек Советы, Җирлек Башлыгы, җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча уздырыла.

Халык яисә Җирлек Советы инициативасы буенча уздырыла торган ачык тыңлаулар Җирлек Советы тарафыннан билгеләнә, Җирлек Башлыгы инициативасы

буенча – Җирлек Башлыгы, ә Җирлек Башкарма комитеты инициативасы буенча – Җирлек Башкарма комитеты".

1.4. 29 маддәне түбәндәге эчтәлектәге 3 пункт белән тулыландырырга:

«п.3.Җирлек халкы санының артуы яисә кимүе белән бәйле рәвештә Җирлек Советы депутатлары санын арттыручы яисә киметүче үзгәрешләр күрсәтелгән үзгәрешләрне кертү турындагы муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән Җирлек Советы вәкаләтләре чыгу белән көченә керә".

2. Гамәлдәге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Гамәлдәге карар 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы №131-ФЗ Федераль законының 44 маддәсендә каралган тәртиптә көченә керә.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы З.И.Нәҗметдинов